КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 5 ноябрь г.Казань № 1014

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 28 март, 112 нче; 2008 ел, 14 апрель, 232 нче; 2009 ел, 1 июнь, 353 нче; 2010 ел, 20 апрель, 279 нчы; 2010 ел, 19 август, 667 нче; 2011 ел, 29 август, 725 нче; 2012 ел, 13 февраль, 110 нчы; 2012 ел, 25 май, 418 нче; 2013 ел, 26 сентябрь, 684 нче; 2014 ел, 6 август, 572 нче; 2015 ел, 2 апрель, 211 нче; 2015 ел, 27 июль, 546 нчы; 2016 ел, 2 ноябрь, 805 нче; 2017 ел, 22 апрель, 237 нче; 2018 ел, 29 гыйнвар, 49 нчы; 2018 ел, 12 июль, 564 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 867 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы

үтенечнамәгә теркәлә торган документлар составына, искәрмәгә түбәндәге эчтәлекле 3 нче пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Гамәлдәге ритуаль эшчәнлек объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерүгә бәйле булган очракларда, бу составның 6 нчы, 8 нче пунктларында, 9 нчы пунктындагы икенче – бишенче абзацларында, шулай ук 12 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыру таләп ителми.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин